**Межрегиональные предметные олимпиады КФУ**
**профиль «Татарский язык»**
**заключительный этап (ответы)**
**2020-2021 учебный год**
**11 класс**

Олимпиада состоит из 8 заданий. Внимательно ознакомьтесь с заданиями и выполните их. Рекомендуем выполнять задания последовательно, но принимаются и ответы, написанные в произвольном порядке.
Ответы можно вводить на компьютере в текстовом редакторе (только используйте татарские буквы) или писать от руки на бумаге. В случае написания ответов от руки необходимо прикрепить фото или скан-копию ответов.

**I. Сүзләрнең русчага тәрҗемәсен языгыз /** Переведите слова на русский язык. *(10 баллов. За каждый правильный вариант по 1 баллу.)*
Дага, иләк, пычкы, тавис кошы, хис, рәшә, сагыш, саз, әсбап, әңгәмә.

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
Дага - подкова, иләк - решето (сито), пычкы - пила, тавис кошы - павлин, хис - чувство (эмоция), рәшә - мираж (марево), сагыш - грусть (тоска), саз - болото, әсбап - пособие (приспособление), әңгәмә - беседа.

**II. [п] һәм [ш]** авазларына билгеләмә языгыз / Дайте определение звукам **[п]** и **[ш].** *(10 баллов. За каждый правильно описанный звук по 5 баллов.)*

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
[п] - ирен-ирен, йомык, саф, шартлаулы, шаулы, саңгырау, авыз тартыгы.
[ш] - тел алды, өрелмәле, шаулы, саңгырау, авыз тартыгы.

**III. Күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз /** Вставьте вместо многоточий нужные буквы. *(10 баллов. За каждый правильный ответ по 1 баллу.)*
...омга, йолд...з, ...гымлы, ...әвеф, к...меш, кор...лма, ...әсрәт, мәнфәгат..., вәг...дә, шәриг...ть.

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
Җомга, йолдыз, ягымлы, хәвеф, көмеш, корылма, хәсрәт, мәнфәгать, вәгъдә, шәригать.

**IV. Җөмләгә 1) синтаксик анализ ясагыз, 2) аның схемасын сызыгыз һәм, 3) төрен билгеләгез.** / Сделайте: 1) синтаксический разбор предложения, 2) укажите схему; 3) определите тип предложения. *(15 баллов. За каждое задание по 5 баллов.)*
Без Алмазлар яши торган Ямашев урамындагы бишенче йортка барып кергән чакта, көн кичкә авышкан иде инде.

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
1) Без 2) Алмазлар яши торган (синт. иярч. аергыч җ.) 1) Ямашев урамындагы бишенче йортка барып кергән чакта (синт. иярч. вакыт җ), 3) көн кичкә авышкан иде инде (баш җ).
Бу – бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.

**V. Тексттан гарәп-фарсы алынмаларын язып алыгыз. /** Выпишите из текста арабо-персидские заимствования. *(10 баллов, по 1 баллу за каждый правильный пример (без повторов))*
Ул заманда, ягъни революция алды елларында, шәкертләрнең яңа әдәбият белән кызыксынуы искиткеч көчәйгән иде. Икмәк шикелле үк зарури бернәрсәгә әйләнеп киткән иде безнең өчен әдәбият!.. Һәр шәкерт төпләп алган калын дәфтәренә җыр күчерә, шигырь күчерә, хәтта романнардан өзекләр дә күчерә. *(Ә. Еники буенча)*

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
Ул **заманда**, **ягъни** революция алды елларында, **шәкертләрнең** яңа **әдәбият** белән кызыксынуы искиткеч көчәйгән иде. Икмәк **шикелле** үк **зарури** бернәрсәгә әйләнеп киткән иде безнең өчен әдәбият!.. **Һәр шәкерт** төпләп алган калын **дәфтәренә** җыр күчерә, **шигырь** күчерә, **хәтта** романнардан өзекләр дә күчерә. *(Ә. Еники буенча)*

**VI. Җөмләдәге фигыльләргә морфологик анализ ясагыз. /** Сделайте морфологический разбор глаголов в предложении. *(10 баллов. За каждый правильный ответ по 2 балла.)*
Юлдан шактый читтә торган күксел урман яныннан узганда, без аның да тынып калырга мәҗбүр иткән кисәтүле тавышын ишеттек.

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
**(читтә) тор**ган – -ган куш. үткән заман сыйфат фигыль, *урман* сүзен ачыклый;
**тынып кал**ырга – тынып + калырга; -ып формалы 1 төр кушымч. хәл фиг.; -ырга формалы инфинитив;
**мәҗбүр ит**кән – кушма фиг., -кән кушымч. үткән заман сыйфат. фиг., тавышын сүзен ачыклый;
**ишет**тек – -те кушымчалы билгеле үткән заман хикәя фиг., 1 зат күплектә.

**VII. Татар әдәби теленең 1) тарихи үсеше, 2) аның этаплары, 3) шул чорларга караган язма истәлекләр турында кыскача языгыз. /** Коротко напишите: 1) об истории развитии татарского литературного языка; 2) об этапах его развития; 3) о письменных памятниках соответствущих периодов. *(15 баллов. Каждый вопрос оценивается 5 баллами)*

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
Татар әдәби теле тарихының чорларга бүленешен түбәндәгечә күрсәтергә мөмкин:
1. Идел буе төркисе һәм борынгы татар әдәби теленең барлыкка килү һәм үсә башлау чоры: Болгар дәүләте әдәби теле (X-XIII гасыр урталары) (“Кыйссаи Йосыф”).
2. Элгәреге (иске) татар әдәби теленең үсү чоры: Алтын Урда дәүләте әдәби теле (XIII гасырның икенче яртысы — XV гасырның беренче яртысы); (Мәхәббәтнамә, Котбның

“Хөсрәү вә Ширин”, Кисекбаш китабы, “Җөмҗөмә солтан”, Сәйеф Сараиның “Гөлстан бит төрки” һ.б.).
3. Элгәреге (иске) татар әдәби теленең нормалашып җитү чоры: Казан ханлыгы чоры татар әдәби теле (XV гасырның икенче яртысы — XVI гасырның уртасы); (Мөхәммәдьярның “Төхфәи мәрдан”, “Нуры содур” һ.б.).
4. Татар милли әдәби теленең үсеше өчен хәзерлек чоры ( XVI гасырның икенче яртысы — XVII-XVIIIгасырлар); (Мәүлә Колый хикмәтләре, Кадыйр Галибәк “Җәмигъ эт тәварих”, Г. Утыз Имәни һ.б.).
5. Татар милли әдәби теленең нормалашу һәм үсеш чоры (XVIII гасыр ахырыннан XX гасыр башына кадәр); (Каюм Насыйри, Гали Чокрый, Фатих Кәрими, Заһир Бигиев, Габдерәхим Утыз-Имәни, Г.Курсави, Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Габдулла Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов һ.б. ).
6. XX гасыр әдәби теле (20нче еллардан хәзерге көнгә кадәр) Г. Ибраһимов, Ш. Усманов, К. Нәҗми, Х. Такташ, А. Шамов, Г. Кутуй, Н. Исәнбәт, Ш. Маннур, М. Җәлил, Х. Туфаннар һ.б.

**VIII. "Ана – бөек исем... Нәрсә җитә ана булуга?! (Һади Такташ)" юллары кайсы әсәрдән алынган? Шушы әсәрдә күтәрелгән идеягә нигезләнеп, 70 сүздән ким булмаган инша язygыз. /«Великое слово - мать... Что может сравниться с ней?» (Хади Такташ)** Напишите, из какого произведения эти строки? Опираясь на идею этого произведения, напишите сочинение (не менее 70 слов). *(20 баллов)*

Әлеге юллар Һади Такташның “Мәхәббәт тәүбәсе” поэмасыннан. Сөйгәне алдап киткән Зөбәйдә бала таба, соңыннан егет үз ялгышын аңлап, Зөбәйдәдән гафу сорый, Зөбәйдә аны кичерә һәм яңа гаилә барлыкка килә. Идея – бала тулы гаиләдә әти-әнисе тарафыннан тәрбияләнеп үсәргә тиеш.

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| *I* | ***Иншаның эчтәлеге.*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| *II* | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге.** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар, | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | **һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы.** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык.*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше.** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән. | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык. | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше.** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык. | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше.** | |
| | Грамматик хаталары юк. | 2 |
| | 1–2 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык. | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше.** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар. | 2 |
| | **2–3** хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык. | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше.** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк. | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк). | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше.** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл.** | | **20** |